КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 март г.Казань № 219

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 5 март, 74 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 5 март, 74 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 18 июнь, 246 нчы; 2009 ел, 19 гыйнвар, 24 нче; 2010 ел, 27 июль, 591 нче; 2012 ел, 2 февраль, 78 нче; 2013 ел, 31 август, 622 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1006 нчы; 2015 ел, 26 сентябрь, 711 нче; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 24 декабрь, 970 нче; 2016 ел, 17 декабрь, 946 нчы; 2018 ел, 26 ноябрь, 1058 нче; 2019 ел, 17 август, 686 нчы; 2020 ел, 3 март, 162 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1253 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1365 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «составын» сүзен «санын һәм составын» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе санын 13 кеше күләмендә;

бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составын.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы коллегиясе составында:

коллегия составыннан Ф.С.Ильинны чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Көнчыгыш-Европа урман тәҗрибә станциясе» Бөтенроссия фәнни-тикшеренү урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру институты» федераль бюджет учреждениесе филиалы директоры Галиуллин Илфир Равил улын (килешү буенча);

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Ягъфәров Азат Фердинанд улын (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин